ГЛАВА
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2018 г.Мензелинск № 119

**Татарстан Республикасында**
гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү территориаль
подсистемасының Минзәлә звеносы турында

1994 елның 21 декабрендә кабул ителгән “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында”гы №68-ФЗ Федераль законы, 2004 елның 08 декабрендә кабул ителгән “Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында”гы №62-ЗРТ Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2003 елның 30 декабрендә кабул ителгән “Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләүнең бердәм дәүләт системасы турында”гы №794 карары, Татарстан Республикасы Министрлр Кабинетының 2004 елның 10 ноябрендә кабул ителгән “Татарстан Республикасында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләүнең бердәм дәүләт системасы турында”гы №480 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район террриториясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү буенча оператив җитәкчелек максатында

## КАРАР ЧЫГАРАМ

1. Түбәндәге документларны расларга:
Татарстан Республикасында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү территориаль подсистемасының Минзәлә звеносы турындагы Положение (Кушымта №1)

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча Комиссия турындагы Положение (Кушымта №2)

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча Комиссия составы (Кушымта №3)

Татарстан Республикасында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү территориаль подсистемасының Минзәлә звеносының даими хәзерлектәге көчләр составы һәм средстволары (Кушымта №4)

Татарстан Республикасында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү территориаль подсистемасының Минзәлә звеносының эшен тәэмин итү буенча функцияләре һәм Минзәлә муниципаль район хезмәтләре һәм оешмалары исемлеге (Кушымта №5)

2. Хосусыйлык формасына карамастан, Минзәлә муниципаль районының оешма, предприятие һәм учреждение җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча тиешле Комиссияләр турындагы Положениене үз объектларында булдырырга һәм расларга;

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча объект комиссияләре составына корректировкаларны вакытында кертергә.

3.Түбәндәге документларны үз көченнән чыккан дип санарга:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район башлыгының 10.08.2016 кабул ителгән “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү территориаль подсистемасының район звеносы турында”гы №83 карары;

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район башлыгының 09.06.2018 кабул ителгән “10.08.2016 кабул ителгән “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү территориаль подсистемасының район звеносы турында”гы №83 карарына үзгәрешләр кертү турында”гы карары.

4. Әлеге карарны контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Минзәлә муниципаль
район Башлыгы

А.Ф.Салахов.